**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Әлши авыл җирлегенең Әлши авылында гражданнар җыены карары**

13 ноябрь 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Әлши авыл җирлегенең Әлши авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2025 елда Әлши авыл җирлегенең Әлши авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзүгә, ремонтлауга, карап тотуга (юлларга вак таш салуга);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны кардан чистарту, җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, Әлши авылында килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү») өчен юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Әлши авыл җирлегенең Әлши авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Әлши авыл җирлеге башлыгы _________ В.Г.Михайлов

Халык җыены секретаре _________ З.А. Гаврилова